КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 16 май г.Казань № 395

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 23 ноябрь, 961 нче; 2012 ел, 15 май, 378 нче; 2014 ел, 11 июнь, 398 нче; 2014 ел, 27 ноябрь, 920 нче;

2015 ел, 17 апрель, 259 нчы; 2015 ел, 14 декабрь, 946 нчы; 2018 ел, 24 июль, 593 нче; 2019 ел, 16 сентябрь, 834 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 нче пунктның җиденче абзацында «муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр һәм авыл җирлегендә» сүзләрен «муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында» сүзләренә алыштырырга;

1.3 нче пунктта:

өченче абзацта «казна» сүзен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләре буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары тиешле эшчәнлек өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы тарафыннан җирле үзидарә органнарының дәүләт хезмәтләре күрсәтүне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләре барлыкка килгән көннән иң күбе 60 календарь көн эчендә эшләнә һәм раслана.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Тиешле эшчәнлек өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы тарафыннан административ регламентлар расланганга кадәр җирле үзидарә органнары, әгәр дә Татарстан Республикасы законы белән башкасы билгеләнмәгән булса, җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләре буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләргә һәм расларга хокуклы.»;

2.3 нчы пунктта:

«в» пунктчасының дүртенче абзацына татар текстында «дәүләт хезмәтләре күрсәтү урыннарында» сүзләре алдына «башкарма хакимият органының, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында,» сүзләрен өстәргә;

«г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитларын һәм рәсми басылып чыккан чыганакларын күрсәтеп) дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында мәҗбүри рәвештә урнаштырылырга тиеш».

Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге административ регламент текстында бирелми.

Административ регламентның бу бүлекчәсендә дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган әлеге норматив хокукый актлар исемлеген тиешле урында урнаштыруга күрсәтмә булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеген үзенең рәсми сайтында, шулай ук «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат

системасының тиешле бүлегендә урнаштыруны һәм актуальләштерүне тәэмин итә»;»;

2.4 нче пунктның «е» пунктчасындагы беренче абзацында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомствосы буйсынуындагы оешмалар» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин